| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от «23» октября 2018** **№ 535**

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 7 июлендәге 214 номерлы “Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентын раслау турында” боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 7 июлендәге 214 номерлы “Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентын раслау турында” (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 12 ноябрендәге 376 номерлы, 2017 елның 18 июлендәге 241 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу

өлкәсендә төбәк дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентын расларга.”.

2. Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентта (алага таба – Регламент):

Регламент исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламенты”;

1 бүлектә:

бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР”;

Бүлекчә исемен һәм 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ИСЕМЕ

1.1. Әлеге Регламент җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен (алга таба бергә – региональ дәүләт контроле) башкарганда Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) таләпләрен, срокларын һәм тәртибен билгели.

Дәүләт функциясе исеме: җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен башкару (алга таба – дәүләт функциясе).”;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3. Министрлык тарафыннан дәүләт функциясен башкару түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (“Российская газета”, 1993 елның 25 декабре, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2002 ел, № 7, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге №181-ФЗ Федераль закон (алга таба – №181-ФЗ Федераль закон) (“Россия

Федерациясе законнар җыелмасы, 1995 ел, №48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы №59-ФЗ Федераль закон (алга таба – №59-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2006 ел, №19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы” 2007 елның 8 ноябрендәге №259-ФЗ Федераль закон (алга таба – №259-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2007 ел, №46, 5555 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2008 ел, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2011 ел, № 17, 2310 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Пассажирларны һәм багажны автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында ташу кагыйдәләрен раслау турында” (алга таба – Кагыйдәләр) 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2009 ел, №9, 1102 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольле органнары тарафыннан юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2010 ел, №28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2015 ел, № 19, 2825 ст.);

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны һәм (яисә) мәгълүматны түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә бу органнардан һәм оешмалардан соратып алуны юллау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия

Федерациясе законнар җыелмасы, 2016, № 17, ст. 2418, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Мәҗбүри таләпләрне бозуның рөхсәт ителмәве турында кисәтү, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлык белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүләрне үтәү турында хәбәрнамә төзү һәм җибәрү кагыйдәләрен раслау хакында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2017 ел, № 8, 1239 ст.);

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә  ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны һәм (яисә) мәгълүматны түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә бу органнардан һәм оешмалардан соратып алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2016, № 18, ст. 2647, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль үткәргәндә юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру хакында»  Россия Федерациясе Прокуратурасының 2009 елның 27 мартындагы 93 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Генераль Прокуратурасының 93 номерлы боерыгы) («Законлылык» басмасы, № 5, 2009,  кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын саклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” 2009 елның 30 апрелендәге №141 номерлы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – №141 Россия икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы) (“Российская газета”, 14 май, 2009 ел, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында” 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Республика Татарстан Дәүләт Советының җыелма басмасы 2011 ел, №10, 1219 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре” турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 317 номерлы карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2005 елның 27 июле, № 28, 0646 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында” 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗномерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында” 2011 елның 6 декабрендәге 999 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2012 елның 13 гыйнвары, №3, 0077 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 20 гыйнварындагы 21 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 21 номерлы ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2018 ел, №7, 0266 ст.);

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыныңТатарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу өлкәсендә административ хокук бозулар турында” беркетмәләр төзүгә һәм эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында” 2012 елның 13 сентябрендәге 156 номерлы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы (алга таба – 156 номерлы Министрлык боерыгы) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2012 елның 19 октябре, №78, 2609 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу, шул исәптән җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны урынга барып тикшерү өчен бу юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән граждан-хокукый мөнәсәбәтләрдә һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормый торган һәм тикшерелә торган затларга йогынты ясарга мөмкин булмаган экспертларны һәм эксперт оешмаларын җәлеп итәргә;

5) юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан законнарның мәҗбүри таләпләрен бозу факты буенча аңлатмалар алырга.»;

«ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРЕП ТОРУЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА МИНИСТРЛЫКНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРЕП ТОРУЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА МИНИСТРЛЫК ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ АЛАРГА ЧИКЛӘҮЛӘР»;

2 бүлектә:

2.21 һәм 2.22 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.21. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, мәҗбүри таләпләр бозылу йә әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек белешмәләр булмаган очракта, Министрлыкның вазыйфаи затлары кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрә ала. Алдан тикшерү барышында гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр җибәргән, мәгълүмат китергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар соратып алына (шул исәптән телдән), юридик затның, индивидуаль эшкуарның Министрлык карамагында булган документлары карала, кирәк булганда, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара эшчәнлектән тыш һәм әлеге затларга мәгълүмат тапшыруны һәм Министрлык таләпләрен үтәүне йөкләми генә, тикшереп тору чаралары үткәрелә. Алдан тикшерү кысаларында алынган мәгълүматка карата юридик заттан, индивидуаль эшкуардан аңлатмалар соратып алырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

2.22. Алдан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрнең бозылуына юл куйган затлар ачыкланганда, мәҗбүри таләпләрнең бозылуы турында йә әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар хакында җитәрлек белешмәләр тупланса, Министрлыкның вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан үткәрелгән тикшерү йомгаклары буенча юридик зат, индивидуаль эшкуар җавапка тартылмый.”;

2.5 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.26. Төбәк дәүләт контролен министр (министр урынбасары) боерыгы нигезендә тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан турыдан-туры хәл ителә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә, административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның 156 номерлы боерыгы белән раслана.

Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә контрольлек итү буенча вәкаләтле, 21 номерлы ТР МК карары белән билгеләнгән, Министрлыкның вазыйфаи затлар исемлеге.”;

3 бүлектә:

1 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «5. Инвалид пассажирларны йөртү һәм аларның йөкләрен ташу хезмәтләрен өстәмә түләү алмый гына күрсәтүгә таләпләр | 5.1. Инвалидлар белән эшләүче белгечләргә җиңел таксида инвалид пассажирларны йөрткәндә һәм аларның йөкләрен ташыганда хезмәтләр күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча инструктаж үткәрү яисә аларны өйрәтү | 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясы | Белгечләргә инструктаж үткәрүне яисә аларны өйрәтүне раслый торган локаль актлар яисә башка документлар |
| | 5.2. Инвалид пассажирга транспортка утырганда һәм транспорттан чыкканда йөртүче тарафыннан ярдәм итү | 259-ФЗ номерлы федераль законның 21.1 статьясындагы 5 пунктының 1 пунктчасы | Белгечләргә инструктаж үткәрүне яисә аларны өйрәтүне раслый торган локаль актлар яисә башка документлар |
| | 5.3. Махсус документы булган очракта, озатып баручы этләрне йөртү | 259-ФЗ номерлы федераль законның 21.1 статьясындагы 5 пунктының 2пунктчасы | Белгечләргә инструктаж үткәрүне яисә аларны өйрәтүне раслый торган локаль актлар яисә башка документлар |
| | 5.4. Инвалид пассажирларның кресло-коляскаларын йөртү | 259-ФЗ номерлы федераль законның 21.1 статьясындагы 5 пунктының 3 пунктчасы | Белгечләргә инструктаж үткәрүне яисә аларны өйрәтүне раслый торган локаль актлар яисә башка документлар |
| | 5.5. Транспорт чарасына эре шрифт, шул исәптән рельефлы-нокталы Брайль шрифты белән эшләнгән язулар, башка текстлы һәм график мәгълүмат урнаштыру | 259-ФЗ номерлы федераль законның 21.1 статьясындагы 6 пункты | Урынга барып тикшерү вакытында җиңел таксиларны документлар таләп итми генә караганда тикшерелә» |

5 бүлектә:

5.9 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җаваплы башкаручы ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән срокларда һәм

тәртиптә (йә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә эшләнгән әлеге Регламентка 8 нче кушымтада күрсәтелгән исемлек нигезендә түләүсез, шул исәптән электрон рәвештә документлар һәм (яисә) мәгълүмат соратып ала.»;

5.10 пунктның икенче абзацындагы дүртенче җөмләсендә «урынга барып тикшерү турында карар кабул итә» сүзләрен «урынга барып тикшерү турында карар кабул итәргә хокуклы» сүзләренә алмаштырырга;

5.40 пунктның дүртенче абзацында «5.5 күрсәтелгән» сүзләрен «5.5 пунктта күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Шикаятькә җавап түбәндәге очракларда бирелми йә андагы мәсьәләнең асылы буенча бирелми:

шикаятьтә юридик зат атамасы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булып торса), шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә кирәк булган почта адресы күрсәтелмәсә;

шикаятьтә Министрлыкныңвазыйфаи затына карата әдәпсез сүзләр яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи зат, шулай ук гаиләсе әгъзалары тормышына, сәламәтлеге һәм милкенә янаулар урын алса (Министрлыкныңвазыйфаи заты шикаятьне җибәргән мөрәҗәгатькә үз хокукыннан кирәгенчә генә файдалану зарурилыгы турында хәбәр җибәрүгә хокуклы);

шикаятьне, почеркы начар булу сәбәпле, укып булмаганда (бу очракта да шикаять тиешле компетенциядәге дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелә алмый, бу хакта шикаять теркәлгәннән соңҗиде көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, аныңфамилиясен (юридик зат атамасы, индивидуаль эшкуар фамилиясе) һәм почта адресын укып булганда);

шикаятьтә алдан җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчегә инде берничә тапкыр язмача җавап бирелеп, шул ук вакытта яңа дәлилләр яки хәлләр китерелмәгән мәсьәләләр урын алса (әлеге шикаять һәм алдан җибәрелгән шикаятьләр шул ук бер дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән очракта. Мөрәҗәгать итүчегә хат язышуны туктату турында хәбәр ителә).
әгәр мөрәҗәгать текстыннан тәкъдимнең, мөрәҗәгатьнең яисә шикаятьнең мәгънәсе аңлашылмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул бу мәсьәлә компетенциясенә карый торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына җибәрелми, бу хакта аны җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң җиде көн эчендә хәбәр ителә;

Министрлыкка яисә вазыйфаи затка 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтына җавап урнаштырылган сорау керсә, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга, аны теркәгәннән соң җиде көн эчендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сорауга җавап урнаштырылган рәсми сайтның адресы җибәрелә, суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать булган очракта, ул кире кайтарылмый.

Шикаятьтә әзерләнелә, кылына торган яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар урын алганда, бу шикаять тиешле компетенциядәге дәүләт органына җибәрелә.

Шикаятьтә суд карарына шикаять белдерелсә, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, шикаять, теркәлгәннән соңҗиде көн эчендә, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә күтәрелгән сорауга җавап бирү дәүләт сере яки федераль закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торган мәгълүматларны таратуга китергән очракта, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә, әлеге мәгълүматларны таратырга ярамау сәбәпле, күтәрелгән сорауга җавап биреп булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән сорауларга җавап биреп булмау сәбәпләре алга таба юкка чыгарыла да, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына янә шикаять җибәрүгә хокуклы.”;

7.12 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Электрон документ рәвешендә алынган шикаятькә җавап шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы аша электрон документ рәвешендә яки шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы аша язмача рәвештә җибәрелә. Моннан тыш, Министрлыкка кергән мөрәҗәгать, ул билгеле булмаган затлар мәнфәгатен кайгырта торган тәкъдимнән, гаризадан яисә шикаятьтән гыйбарәт булса, аерым алганда, билгеле булмаган затларга карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелсә, җавап, шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 6 өлеше нигезендә «Интернет» челтәренә урнаштырылырга мөмкин;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 8 кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының Җиңел таксида
пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өлкәсендә төбәк
дәүләт контролен һәм җиңел таксида пассажирлар
йөртү һәм йөк ташу хезмәтләреннән
инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин
итүгә контрольлек итү буенча дәүләт функцияләрен
башкаруның административ регламентына
8 нче кушымта

## ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫ КАРАМАГЫНДА БУЛГАН ДОКУМЕНТЛАРНЫ ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТНЫ ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТ АЛМАШУ КЫСАЛАРЫНДА МИНИСТРЛЫК ТАРАФЫННАН ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРГӘНДӘ СОРАТЫП АЛЫНА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТ ИСЕМЛЕГЕ

| Соратып алына торган документ һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге | Соратып алына торган документ һәм (яисә) мәгълүмат үз карамагында булган дәүләт органы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте”. |

Министр в.б. А.В. Егоров